РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«20» декабрь 2021 ел Олы Кайбыч ав. №91

**Төзекләндерү өлкәсендә предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү булган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен кабул итү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу тора торган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләре Советларының Төзекләндерү өлкәсендә предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү булган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен кабул итү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу тора торган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәрен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләре Советлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А. И. Рәхмәтуллин